МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.06.2023 Казан ш № 498

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 21 июлендәге 488 номерлы боерыгы белән расланган Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының аерым категория гражданнары өчен гамәлгә кертү турында» 2022 елның 17 августындагы 786 номерлы боерыгына үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 16 мартындагы 376 номерлы карарының 2 пунктына үзгәреш кертү турында» 2023 елның 29 маендагы 865 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш

белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 21 июлендәге 488 номерлы боерыгы белән расланган Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының аерым категория гражданнары өчен гамәлгә кертү турында» 2022 елның 17 августындагы 786 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 28 декабрендәге 1142 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) үзгәреш кертеп, 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе яки Херсон өлкәсе территорияләрендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм торган урыны буенча мәшгульлек хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән Россия Федерациясе гражданнары;

2022 елның 30 сентябренә кадәр Донецк Халык Республикасы яки Луганск Халык Республикасы гражданлыгына ия булган гражданнар, Украина гражданнары һәм Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе яки Херсон өлкәсе территорияләрендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм торган урыны буенча мәшгульлек хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән, гражданлыгы булмаган затлар.».

2. Әлеге боерыкның гамәлдә булуы 2023 елның 10 июненнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова